

# Хөсәенов Фәйзелгаян Нәһерлегаян улы

## (1948-2007)

Хөсәенов Фәйзелгаян Нәһерлегаян улы 1948 елның 25 маенда Актаныш районы (элек Калинин районы дип йөрткәннәр) Әтәс авылында укытучы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Җиденче сыйныфка кадәр үз авылларында белем ала. 1962 елда гаиләләре Мөслим районы Үрәзмәт авылына күченеп китә. Үрәзмәт мәктәбендә 8 сыйныфны тәмамлап, 1963-1967 елларда Минзәлә педагогия училищасында укытучы һөнәре үзләштерә. 1967 елда яшь белгеч Мөслим РОНОсына инспектор булып билгеләнә. Әтисе Нәһерлегаян абый да, әнисе Әския апа да тормыш юлларын балалар укытуга багышлаган. 1969 елда Метрәй мәктәбендә рус теле укыта. 1970 елда Усы кызы Клара апа(шулай ук укытучы) белән гаилә корып җибәрәләр. Яңа Усы мәктәбендә рус теле укыта. 1971 елда Баек мәктәбенә директор итеп билгеләнә. 1975-1985 елларда Тат Шуран авылында җитәкче, мәктәп директоры булып эшли. 1985-1987 елларда Яңа Усы мәктәбендә директор итеп билгеләнә. 1987 елда гаиләләре белән Яр Чаллы шәһәренә күченеп китәләр. Яр Чаллы укыту-җитештерү комбинатында директор булып эшли. Тормыш иптәше Клара апа белән өч кыз тәрбияләп үстерүләр. 2007 елның 5 мартында 59 яшендә Чаллы шәһәрендә вафат була.